***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА

# БИРЕМНӘРЕ

(2024-2025 нче уку елы)

**10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 68**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге [**ө**] авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Йолдыз бик югары да, ул да кое төбенә төшә.* (Мәкаль)
а) 2
ә) 3
б) 4
в) 5

2. Җөмләдәге ачык иҗекләр санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Ялкау ятып эшли, утырып йоклый.* (Мәкаль)
а) 3
ә) 4
б) 5
в) 6

3. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
***мыегы үрә тору***
а) бик каты мактану
ә) бик каты шатлану
б) бик каты ачуы килү
в) бик каты борчылу

4. Татар теленең үз сүзен билгеләгез. **(2 балл)**
а) келәм
ә) диван
б) өстәл
в) суыткыч

5. Җөмләдәге тамыр сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Иртәгәге эшеңне бүген эшлә.* (Мәкаль)
а) иртәгәге
ә) эшеңне
б) бүген
в) эшлә

6. Юклык алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

а) минеке
ә) ничек
б) һәрбер
в) һичкем

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

***Кумәк*** *эш – күңелле эш.* (Мәкаль)

а) сыйфат
ә) исем
б) рәвеш
в) фигыль

8. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Курыккан эт* ***кырга*** *чыкмас.* (Мәкаль)

а) ия
ә) тәмамлык
б) урын хәле
в) рәвеш хәле

9. Икеләнүне белдерә торган кереш сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) зинһар
ә) мөгаен
б) ниһаять
в) ичмасам

10. Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Малай, кулына акча керсә, көчек сатып алыр.* (Мәкаль)

а) синтетик иярчен урын җөмлә
ә) синтетик иярчен вакыт җөмлә
б) аналитик иярчен шарт җөмлә
в) синтетик иярчен шарт җөмлә

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

Уңай һәм _____________ ассимиляция була. Элек тә һәм хәзерге көндә дә еш кулланыла торган сүзләр _____________ сүзләр дип атала. Тамыр нигезле һәм _____________ нигезле сүзләр була. Исем килеш, сан һәм _____________ белән төрләнә. Гарәп цифрларыннан соң килгән кушымчалар _____________ языла. Боерык фигыль _____________ белән төрләнми. –ның/-нең кушымчалы сүз җөмләдә исемгә иярсә, ул _____________ була. Мөнәсәбәтле сүз һәрвакыт _____________ җөмләдә килә.

### III. Башыгызны эшләтегез.

Сүзләрне дөрес итеп урнаштырып, ике мәкаль языгыз. **(4 балл)**

*булыр, кешенең, чыкмас, ялкауның, чокыр, куеныннан, җилкәсе, ялкау, кулы*

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

### IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**

Я увидел ёлку. Росла она в тени, и оттого сучья у неё были опущены вниз. Под ёлкой получился хороший шалашик.

Невозможно передать прелести пребывания в лесу под ёлкой во время тёплого летнего дождя. Долго дождик шептал и шептал что-то нашей ёлке. *(М.Пришвин)*

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

САКЛЫЙК, ӘЙДӘ, ҖИР-АНАНЫ

Чиста һава – җанга дәва, беләбез,
Сихәт эзләп, урманнарга керәбез.
Сафланырга шәһәр сарган сөремнән
Елга-күлләр хозурына киләбез.
Кошлар тынса, урман бетсә, күл кипсә,
Җирдә яшәү булалмасын төшенәм.
**Я, кем белә: ничек итеп якларга**
**Зур Җир шарын бәп-бәләкәй кешедән**?

(*Сания Әхмәтҗанова*)

2.1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)** __________________________________________

2.2. Кече тел ассимиляциясе күзәтелгән сүзне күчереп языгыз. **(1 балл)**

______________________________________________________________________________

2.3. Шигырьдә кулланылган синонимнарны языгыз. **(1 балл)**

______________________________________________________________________________

2.4. 1-2 җөмләләрдәге затланышсыз фигыльләрне күчереп языгыз. **(3 балл)**

______________________________________________________________________________

2.5. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләгә синтаксик анализ ясагыз: баш кисәкләрнең астына сызыгыз, компонент чикләрен билгеләгез, схема сызыгыз, җөмләгә билгеләмә бирегез. **(4 балл)**

______________________________________________________________________________

3. ***“Җир-ананы саклыйк!”*** дигән темага 10-12 җөмләдән торган инша языгыз. **(15 балл)**